**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об учреждении премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан»

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 3 июля 2015 года № УП-619 «Об учреждении премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 4 июня 2016 года № УП-503, от 3 июня 2017 года № УП-460, от 27 января 2018 года № УП-109, от 17 ноября 2018 года № УП-778, от 21 июля 2020 года № УП-432, от 25 ноября 2020 года № УП-778 и от 21 июня 2021 года № УП-503) следующие изменения:

а) в пункте 7 Положения о премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан:

в абзаце первом слова «25 календарных дней» заменить словами «35 календарных дней»;

абзац третий подпункта «б» после слова «отчество» дополнить словами «(при наличии)»;

б) в составе Комитета по присуждению премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан (далее – Комитет):

вывести из состава Комитета М.Ш. Сибгатуллину;

ввести в состав Комитета Синеглазову Анну Григорьевну – руководителя государственного казенного учреждения «Аппарат Общественной палаты Республики Татарстан», утвердив ее секретарем Комитета;

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

А.Л. Вяткиной – «генеральный директор государственного бюджетного учреждения культуры «Национальный музей Республики Татарстан» (по согласованию)»;

О.В. Пелевина – «первый заместитель министра экономики Республики Татарстан».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
08 июля 2022 года
№ УП-470

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданжәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-432 номерлы һәм 2021 елның 21 июнендәге ПУ-503 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турында нигезләмәнең 7 пунктында:

беренче абзацта «25 календарь көн» сүзләрен «35 календарь көн» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасының өченче абзацына «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан М.Ш. Сибгатуллинаны чыгарырга;

Комитет составына, Комитет секретаре итеп раслап, Синеглазова Анна Григорьевнаны – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесен кертергә;

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Л. Вяткинаның – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры (килешү буенча)»;

О.В. Пелевинның – «Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ГОМУМИ БҮЛЕК ОТДЕЛ ОБЩИЙ АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 08 июль
№ ПУ-470